КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 июль г.Казань № 682

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын үткәрү турында» 2017 ел, 27 май, 313 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 24 гыйнвар, 32 нче; 2018 ел, 20 июнь, 501 нче; 2020 ел, 21 февраль, 124 нче; 2020 ел, 10 апрель, 268 нче; 2020 ел, 25 июнь, 527 нче; 2021 ел, 21 июнь, 491 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Иң яхшы муниципаль практика» бөтенроссия конкурсының республика этабын оештыру һәм үткәрү буенча республика комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

конкурс комиссиясе составыннан А.Ә.Кәримовны чыгарырга;

конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры Олег Владимирович Коробченконы кертергә;

Илнур Мәхмүт улы Гариповның вазыйфа атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесенең беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин